**Татар теленнән 2 нче сыйныф өчен эш программасына аннотация**

Эш программасы Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. - ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре, Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль гомуми белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту планына нигезләнеп эшләнде.

Татар теле филология өлкәсенә карый. Татар теле фәне 2 нче сыйныфта атнага 3 сәгать исәбеннән 102 сәгать укытыла.

**Каралды**
**Башлангыч сыйныф укытучыларының мәктәп методик берләшмә җитәкчесе__________Тухбатуллина Э.М.**
**Беркетмә № 1**
**« 26 » август 2017 ел.**

**Килешенгән**
**Укыту эшләре буенча директор урынбасары**
**_____ Исмәгыйлева Г.Т.**
**« 28 » август 2017 ел**

**Раслыйм**
**Мәктәп директоры**
**________ Сабирҗанова Г.Т**
**Приказ №71**
**«28 » август 2017 ел**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**" Сарман гомуми урта гомуми белем бирү мәктәбе"**
**муниципаль гомуми белем бирү бюджет учреждениесе**

**Татар теленнән**
**эш программасы**

**2 нче сыйныф**

**Сабирова Чулпан Рамил кызы**
**башлангыч сыйныф укытучысы**

Каралды
Мәктәп педагогик советы
утырышы беркетмәсе № 1
«28» август, 2017 ел

**2017 – 2018 нчы уку елы**

**Татар теле буенча**
**укыту-тематик планлаштыру**

**Сыйныф** - 2 а

**Сәгатьләр саны**: барлыгы – 102 сәгать; атнага – 3 сәгать.

Эш программасы- -Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008;
-Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.;
- үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә;
-“Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа” сына -1 – 4 нче сыйныфлар, Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Казан , 2011;
- «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту планына нигезләнеп эшләнде.

.**Дәреслек:** — Мияссарова И.Х., Фәйзрахманова»»".Ф. Татар теле: 2 нче сыйныф: дәреслек: 1 — 2 кисэк. Казан: «Магариф — Вакыт» нэшрияты, 2012.
— Мияссарова И.Х., Фәйзрахманова К.Ф. Татар теле: мөстәкыйль эш дәфтәре. Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2015

## Аңлатма язуы

Эш программасы Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. - ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре, Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту планына нигезләнеп эшләнде.

Тәкъдим ителә торган программада татар теленә өйрәтүнең **төп максаты** һәм **бурычлары** түбәндәгедән гыйбәрәт:

1.Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнергә теләк уяту, үз милләтенә, теленә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.

2.Балаларга татар теленең төрле бүлекләре буенча белем бирү:

а) фонетика, орфоэпия, лексика, грамматикага караган белемнәрне тирәнәйтү;

б) телебезнең грамматикасы, орфографиясе, пунктуациясе буенча күнекмәләр булдыра башлау. Сүз, сүзләрдән сүтезмәләр һәм җөмләләр төзергә өйрәтү, җөмлә төзүче баш кисәкләр белән таныштыру. Җөмләләрнең мәгънәви-интонацион үзенчәлекләрен күзәтү һәм җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен кую.

3.Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.

4. Укучыларда дөрес уку һәм язу күнекмәләре булдыру, тасвирлама, хикәяләү, фикер йөртү төрендәге кечкенә текстлар төзергә өйрәтү.

5. Укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү.

## Предметның укыту планындагы урыны

Татар теле филология өлкәсенә карый. Татар теле фәне 2 нче сыйныфта атнага 3 сәгать исәбеннән 102 сәгать укытыла.

**Искәрмә:** «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында»гы 2016 нчы елның 29 нчы августында педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килгән очракта, программа сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

## Укыту предметын үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләре

**Укучылар башкара алырга тиешле эшләр:**

-сүзләрне, җөмләләрне, 35-40 сүзле текстны, хәрефләрен бозмыйча, төшереп калдырмыйча, хәреф өстәмичә, урыннарын алыштырмыйча, аңлаешлы, пөхтә итеп, каллиграфик дөрес язу;

-сузык һәм тартык авазларны, калын (нечкә) сузыкларны икеләнүсез аеру; өйрәнелгән теориягә таянып, аларга анализ ясау, бирелгән аваз схемасына, характеристика тиешле авазлар, сүзләр сайлау;

-сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм, иҗекләп, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләренең катгый булмавын аңлау (аларның вариантларын белү);

-сүздә шул хәрефләрнең эшен, вазыйфасын аңлату;

-өйрәнелгән сүзләрдә калын(нечкә) тартыкларны сузык аваз хәрефләре яки ь, ъ белән күрсәтү;

-кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга атамаларын, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу;

-е, в, г, й, к, н, ң, о, ө, х, һ, э, ю, я хәрефләре, ый, йо, йө кушылмалары булган сүзләрне дөрес язу;

-янәшә килгән бертөрле ике тартык аваз хәрефләре булган әллә, кәккүк, Габбас кебек сүзләрне, нечкә (калын) аеру билгесе кергән гади, программада булган сүзләрне дөрес язу һәм юлдан-юлга күчерү;

-сүзгә фонетик анализ ясау:иҗекләргә бүлү, авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес итеп әйтеп, хәрефләрен атап чыгу, сузык (тартык) авазларны билгеләү, сузыкларның калын(нечкә) төрләрен аеру;

-үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштырып төзәтү;

-сүзләргә дөрес сорау кую һәм шуның нигезендә предметны, предметның эш һәм хәрәкәтен, билгесен белдергән сүзләрне таба белү, кем? нәрсә? сорауларына җавап биргән сүзләрне аера белү;

-җөмләнең баш кисәкләрен табу, җөмләдәге сүзләр бәйләнешен билгеләү; җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, әйтелү максатына карап, җөмлә ахырында нокта, сорау билгеләрен куеп яза белү;
-уку, уеннар, көндәлек тормыш, җәнлекләр, кош-кортлар турындагы темаларга 4-5 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп сөйләү һәм язу;
-сүзлекләрдәге сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: *аваз, авыз, авыл, бәрәңге, бияләй, борын, вакыт, гомер, гыйнвар, дөрес, дүшәмбе, елга, җавап, җиңел, җомга, җөмлә, җылы, йөрәк, караңгы, көньяк, кыңгырау, маңгай, Мәскәү, муен, онык, оя, пәнҗешәмбе, савыт, сәгать, сәлам, сеңел, сишәмбе, тавык, тавыш, тәмле, төньяк, уен, уңыш, хайван, хөрмәт, һава, һаман, чаңгы, чәршәмбе, чия, шәһәр, шуа, эссе, юан, якшәмбе.*

**Шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләр**

Шәхси нәтиҗәләр:
- туган илгә карата шәхси караш булдыру;
- чын кеше сыйфатлары булдыру;
- мөстәкыйльлелек һөм җаваплылык үстерү;
- этик хисләр, мөлаемлылык үстерү;
- рухи-әхлакый идеалларына китерү.
- олылар белән хезмәттәшлек;
- аралашу культурасы күнекмәләре .

Метапредметлы нәтиҗәләр:
- аң -белем үстерү;
- проблемаларны мөстәкыйль рәвештә таба алу;
- эзләнү юлларын һөм нәтиҗәләрен ачыклау;
- логик фикерләү:чагыштыру,синтез, анализ ясый белү;
- конфликтлы ситуацияләрдән чыгу юлын табу;
- укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү;

Предметлы нәтиҗәләр:
- Россиядә күп милләт халыкларының төшенчәсен бирү;
- татар теленең төп төшенчәләр буенча башлангыч белем ( фонетик, лексик, грамматик);
- татарча югары сөйләм культурасы формалаштыру;
- туган телнең орфоэпик, лексик, грамматик төшенчәләре;
- сүз турында башлангыч төшенчәләр формалаштыру;
- уку, язу гамәлләре формалаштыру;
- сүзгә фонетик анализ ясый белү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**
- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;

- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңнеконтрольгәалу, биремнеүтәүнеңдөреслеген тикшерү;
- тормыштәҗрибәсенкуллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:**

- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үзуңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үзэшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

## Укыту предметының, темаларының эчтәлеге

**Фонетика һәм орфоэпия (34 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Беренче сыйныфта алган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне ныгыту, тирәнәйтү.

Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Язуда сузык авазларны белдерә торган хәрефләр.

Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан-юлга күчерү. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Парлы һәм парсыз яңгырау-саңгырау тартыклар. Язуда тартык авазларны белдерә торган хәрефләр. Татар теленә хас үзенчәлекле авазлар.

*Е, ю, я* хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү һәм шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, язу.

Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы.

Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүе.

***ъ*** һәм ***ь*** хәрефләренең аваз белдермәгәнен истә тоту, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес язу.

Татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес итеп яттан белү. «Дөрес әйт», «Дөрес яз», «Аңлатмалы сүзлек» белән эшләгәндә, алфавиттан файдалану. Беренче хәрефкә карап, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру.

**Эш формалары:** төркемдә һәм парларда, иҗади эшләр.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Укучылар э-е, ө-е, о-ы, я, ю, е хәрефләренең сүзнең төрле урыннарында дөрес язылышын, рус теленнән кергән сүзләрне дөрес итеп укый, күчереп һәм ишетеп яза; яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аера белергә, в хәрефе кергән сүзләрне дөрес укырга, калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрдә к, г хәрефләрен дөрес әйтә,***ъ*** һәм ***ь*** хәрефләренең аваз белдермәгәнен истә тотып, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес яза;сүзләрне иҗекләргә һәм юлдан-юлга күчерү өчен бүлә;татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес итеп яттан белә; «Дөрес әйт», «Дөрес яз», «Аңлатмалы сүзлек» белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана; беренче хәрефкә карап, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыра белергә тиешләр.

**Контроль төрләре:** парларда яки үз-үзеңне тикшерү, сүзлек, искәртмәле, аңлатмалы, ирекле диктантлар, контроль күчереп язу, контроль диктантлар.

**Мөстәкыйль эшләр:**биремле күчереп язу, дидактик биремнәр.

**Графика (4 сәгать)**

Татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес итеп яттан белү. “Дөрес әйт”, “Дөрес яз”, “Аңлатмалы сүзлек” белән эшләгәндә, алфавиттан файдалану. Беренче хәрефкә карап, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру.

**Сүз (38 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Сүз тамыры. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар. Татар телендә сүз тамырының сүз башында булуын, үзгәрмәвен, кушымчаларның тамыр сүзгә сингармонизм законына бәйле рәвештә ялганып килүен гамәли күзәтү.

Предметны белдергән сүзләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.

Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр. Аларның җөмләдә сүзләрне үз тирәсенә туплаган үзәк булуына төшенү.

Предметларның төрле билгеләрен атаган сүзләр. Аларны, Нинди? Кайсы? сорауларын куеп, сүзләр арасыннан табу, җөмләдәге ролен гамәли күзәтү.

**Эш формалары:** төркемдә һәм парларда, иҗади эшләр.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Укучылар сүзнең тамырын, кушымчаларын аера,тамырдаш сүзләр таба, предметны, предметның билгесен, предметның эш-хәрәкәтен белдергән сүзләрне аера һәм җөмләдән таба, уртаклык һәм ялгызлык исемнәрнең язылышынбелергәтиешләр.

**Контроль төрләре:**парларда яки үз-үзеңне тикшерү, искәртмәле һәм аңлатмалы, ирекле диктантлар, контроль күчереп язу, контроль диктантлар, тест эшләү.

**Мөстәкыйльэшләр:**биремле күчереп язу, дидактик биремнәр.

**Җөмлә (10 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аера белү. Җыйнак һәм җәенке гади җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрләре, аларны дөрес интонация белән әйтү.

**Эш формалары:** төркемдә һәм парларда, иҗади эшләр.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Укучылар җөмләләрне, тыныш билгеләренә карап, җөмләнең төрләрен билгели, дөрес интонация белән укый; сүз, сүзтезмә, җөмләне аера, җөмләнең баш кисәкләрен күрсәтә белергә тиешләр.

**Контроль төрләре:**парларда яки үз-үзеңнетикшерү, ирекле диктант, контроль күчереп язу.

**Мөстәкыйль эшләр:** дидактик биремнәр.

**Бәйләнешле сөйләм (13 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Бәйләнешле сөйләмдә җөмләләрнең үзара бәйләнеше. Бер темага берләштерелмәгән аерым җөмләләрне текст белән чагыштыру. Текстның темасын билгеләү. Текстны кисәкләргә бүлү. Текст кисәкләренә исем кую.

Сюжетлы рәсемнәр буенча бер темага берләштерелгән җөмләләр төзү һәм язу.

Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау. Татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану.

**Эш формалары:** төркемдә һәм парларда, иҗади эшләр.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Укучылар бәйләнешле сөйләмдә җөмләләрнең үзара бәйләнешен,телдән һәм язма сөйләмнең үзенчәлекләрен, рәсем буенча җөмләләр һәм хикәя төзи, текстның темасын билгели, кисәкләргә бүлә һәм текст кисәкләренә исем куя, хат һәм котлау открыткасы яза белергә тиешләр.

**Контроль төрләре:**парларда яки үз-үзеңне тикшерү, аңлатмалы һәм контроль диктант.

**Мөстәкыйльэшләр:**биремле күчереп язу, дидактик биремнәр.

**Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау (3 сәг.)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Авазлар һәм хәрефләрне; сүз, тамыр һәм кушымчаны;предметны, билгене, эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләрен,текст һәм текстның өлешләрен кабатлау.

**Эш формалары:** төркемдә һәм парларда, иҗади эшләр.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Укучылар авазлар һәм хәрефләрне; сүз, тамыр һәм кушымчаны;җөмлә һәм җөмлә янында тыныш билгеләрен; предметны, билгене, эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләрен,текст һәм текстның өлешләрен аера, таба белергә тиешләр.

**Контроль төрләре:** тест эшләү, парларда яки үз-үзеңне тикшерү.

**Мөстәкыйль эшләр:** дидактик биремнәр.

Дөрес әйтелеше, язылышы уку елы дәвамында гамәли үзләштерелергә тиешле сүзләр:

*аваз, авыз, авыл, бәрәңге, бияләй, борын, вакыт, гомер, гыйнвар, дөрес, дүшәмбе, елга, җавап, җиңел, җиңү, җомга, җөмлә, җылы, йолдыз, йөрәк, караңгы, көньяк, кыңгырау, маңгай, Мәскәү, муен, онык, оя, пәнҗешәмбе, савыт, сәгать, сәлам, сеңел, сишәмбе, тавык, тавыш, тәмле, төньяк, уен, уңыш, хайван, хөрмәт, һава, һаман, чаңгы, чәршәмбе, чия, шәһәр, шуа, эссе, юан, якшәмбе*

**Календарь-тематик планлаштыру**

| | Дәрес темасы | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1 | “Тылсымчы китапханәсенә рәхим итегез. “Дөрес әйт” һәм “Дөрес яз” сүзлеге | Дәреслек белән эшләү. Шартлы билгеләрне истә калдыру. Сүзлекләр белән эшләү. Телдән һәм язма күнегүләр эшләү. | 1.09 | 4.09 |
| 2 | Авазлар һәм хәрефләр | Сүздән авазны аера белү, аңа характеристика бирү. Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. Сүзгә аваз-хәреф анализы ясау. Дәреслектәге күнегүләрне төгәл үтәү. Белемнәрне тикшерү. | 4.09 | |
| 3 | Авазлар һәм хәрефләр | | 6.09 | 6.09 |
| 4 | Сузык авазлар. | Дәреслектәге һәм карточкадагы күнегүләрне үтәү. Фонетик зарядка ясау. Төркемнәрдә эшләү. Нәтиҗәләр ясау. | 8.09 | 8.09 |
| 5 | Калын һәм нечкә сузыклар | Сузык авазларның әйтелеш үзенчәлекләрен аңлату. Күнегүләр эшләү. Сузык авазларны чагыштыру. Өлешчә эзләнү, нәтиҗә ясау. Теманы билгеләү. Максатны ачыклау. Калын (нечкә) сузык авазларны икеләнүсез аеру, аларга анализ ясау. | 11.09 | 11.09 |
| 6 | О, ы хәрефләре | Фонетик зарядка ясау. Орфоэпик күнегүләр үтәү, «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» белән эшләү. | 13.09 | 13.09 |
| 7 | Кереш контроль эш (диктант). | Диктант язу, дөреслеген тикшерү, биремне үтәү. | 15.09 | 15.09 |
| 8 | Ө, е хәрефләре | Ө,е хәрефе булган сүзләрне язу. Сүзләргә аваз-хәреф анализы ясау. “Дөрес әйт”,”Дөрес яз” сүзлекләре белән эшләү. | 18.09 | 18.09 |
| 9 | Э, е хәрефләре | Язуда э хәрефенең язылу урынын күзәтү. Татар телендә һәм алынма сүзләрдә э хәрефенең яңгырашы. “Аңлатмалы сүзлек” белән эшләү. Э хәрефенең сүз башында һәм сүз уртасында язылу очракларын күзәтү. Күнегүләр эшләү | 20.09 | 20.09 |
| 10 | Кереш контроль күчереп язу | Контроль күчереп язу, бирем эшләү. Дөреслеген тикшерү | 22.09 | 22.09 |
| 11 | Хаталар өстендә эш. Иҗек. | Хаталар өстендә эшләү. Әңгәмә кору, фонетик зарядка ясау, орфоэпик күнегүләр үтәү, «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» белән эшләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм, иҗекләп, юлдан юлга күчерүнең катгый булмавын, аларның вариантларын кабатлау. Күнегүләр эшләү | 25.09 | 25.09 |
| 12 | Сүзләрне юлдан-юлга күчерү | Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Юлдан -юлга күчерүнең вариантларын кабатлау. Күнегүләр эшләү. Дәреслектәге күнегүләрне төгәл үтәү. | 27.09 | 27.09 |
| 13 | Сүзләрне юлдан-юлга күчерү | Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. Иҗекләргә төрле иҗекләр өстәп, сүзләр язу. Икенче юлга күчерергә ярамый торган сүзләр язу. Дәреслектәге һәм карточкадагы күнегүләрне үтәү. Дәреслектәге күнегүләрне төгәл үтәү. | 29.09 | 29.09 |
| 14 | “Сузык авазлар” темасы буенча диктант «Болыт”. | Татар телендәге яңгырау һәм саңгырау тартыклар таблицасын төзү, форзацтагы таб-лица белән эшләү, рус теле белән чагыштыру, биремнәрне үтәү. Биремнәрне парларда тикшерү. Гел яңгырау һәм саңгыраулардан гына торган сүзләр язу. | 2.10 | 2.10 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15 | Хаталар өстендә эш. Тартык авазлар. | Бирелгән аваз схемасына туры килгән сүзләр сайлау. Дәреслектәге күнегүләрне төгәл үтәү.<br>Сүзләрне схемада күрсәтеп язу. Борын авазларын дөрес әйтеп уку. | 4.10 | 4.10 |
| 16 | М, н, ң хәрефләре | В хәрефенең [в] һәм [w]авазларына бүленүен икеләнүсез аеру. Бу аваз кергән сүзләрне дөрес әйтү; [в] һәм [w]авазлары булган сүзләрне дөрес язу. | 6.10 | 6.10 |
| 17 | В хәрефе | К,г хәрефләре кергән сүзләрне дөрес итеп әйтеп уку; Дәреслектәге күнегүләрне төгәл үтәү.<br>Сүзлекләр белән эшләү. Сүзләргә аваз-хәреф анализы ясау. | 9.10 | |
| 18 | К, г хәрефләре | Калын укылышлы сүзләрдә к,г авазларын күзәтү. Сүзлекләр белән эшләү.<br>Сүзлек диктанты язу. Сүзләргә аваз-хәреф анализы ясау. Телдән һәм язма күнегүләр эшләү. | 11.10 | |
| 19 | К һәм г хәрефләрен калын уку өчен ъ хәрефен язу. Контроль сүзлек диктант | Х, һ хәрефләре булган сүзләрне дөрес язу.Тизәйткечләр ятлау. Телдән һәм язма күнегүләр эшләү. «Кайсы сүз артык?» уенын уйнау. Өлешчә эзләнү. | 13.10 | |
| 20 | Х, һ хәрефләре | Дәрес темасын, максатын билгеләү. Телдән һәм язма күнегүләр эшләү. Фонетик зарядка ясау, Үтелгән материал буенча сорауларга җавап бирү. | 16.10 | |
| 21 | Й хәрефе | Й хәрефе сүз башында булган сүзләрне дөрес язу. Сүзлекләр белән эшләү. Бирелгән аваз схемасына туры килгән сүзләр сайлау. Телдән һәм язма күнегүләр эшләү. | 18.10 | |
| 22 | Й хәрефе сүз башында | Й хәрефе сүз башында булган сүзләрне дөрес язу. Сүзлекләр белән эшләү. Бирелгән аваз схемасына туры килгән сүзләр сайлау. | 20.10 | |
| 23 | «Тартык авазлар» темасы буенча контроль диктант “Бакчада”. | Диктант язу, дөреслеген тикшерү, биремне үтәү. Кагыйдәләрне кабатлау, грамматик-орфографик анализ ясау. | 23.10 | |
| 24 | Е хәрефе. | Фонетик зарядка ясау. Дәреслектәге биремнәрне үтәү. Бирелгән аваз схемасына туры килгән сүзләр сайлау. Күнегүләр эшләү, сузыкларны чагыштыру, өлешчә эзләнү, | 25.10 | |
| 25 | Я хәрефе. Хаталар өстендә эш. | Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. “Аңлатмалы сүзлек” белән эш. Дәреслектәге күнегүләрне үтәү. Теманы билгеләү. Максатны ачыклау | 27.10 | |
| 26 | Я хәрефе темасын ныгыту | Дәреслектәге күнегүләрне төгәл үтәү. Сузыкларны чагыштыру. Бирелгән аваз схемасына туры килгән сүзләр сайлау. Теманы билгеләү. Максатны ачыклау. | 6.11 | |
| 27 | Ю хәрефе. | Фонетик зарядка ясау, дәреслектәге биремнәрне үтәү, чагыштыру. Бирелгән аваз схемасына туры килгән сүзләр сайлау. Күнегүләр эшләү. Сузыкларны чагыштыру. Өлешчә эзләнү. | 8.11 | |
| 28 | Ю хәрефе темасын ныгыту | | 10.11 | |
| 29 | Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы | Хаталар өстендә эш эшләү. Фонетик зарядка ясау. Орфоэпик күнегүләр үтәү. Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы буенча модель төзү. Дәреслектәге күнегүләрне төгәл үтәү. | 13.11 | |
| 30 | Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы | Теманы билгеләү. Максатны билгеләү. Дәреслектәге күнегүләрне төгәл үтәү. Яңа материал буенча сорауларга җавап алу, нәтиҗә ясау. | 15.11 | |
| 31 | Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүе | Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүче сүзләр эзләп табу. Әлеге сүзләрне юлдан-юлга дөрес күчерү буенча күнегүләр эшләү. | 17.11 | |
| 32 | ь хәрефе (нечкәлек һәм аеру билгесе) | Теманы,максатны билгеләү. ь билгесе кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү,мондый сүзләрнең аваз(хәреф)санын дөрес санау күнегүләре эшләү. | 20.11 | |
| 33 | ь хәрефе (нечкәлек һәм аеру билгесе) | Нечкә иҗек ахырында я, ю, е хәрефләре алдыннан килгән нечкәлек билгесенең вазифасын билгели белү. Теманы билгеләү. Максатны билгеләү. Дәреслектәге | 22.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | күнегүләрне эшләү. | | |
| 34 | Нечкә иҗек ахырында я, ю, е хәрефләре алдыннан килгән нечкәлек билгесе | Нечкә иҗек ахырында я, ю, е хәрефләре алдыннан килгән нечкәлек билгесенең вазифасын билгели белү. Дәреслектәге күнегүләрне эшләү | 24.11 | |
| 35 | Нечкә иҗек ахырында я, ю, е хәрефләре алдыннан килгән нечкәлек билгесе | Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. ъ билгесе кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү,мондый сүзләрнең аваз(хәреф)санын дөрес санау күнегүләре эшләү,транскрипцияләү. | 27.11 | |
| 36 | ъ хәрефе (калынлык һәм аеру билгесе) | | 29.11 | |
| 37 | ъ хәрефе (калынлык аеру билгесе) Контроль сүзлек диктанты | Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. ъ билгесе кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү Сүзләрнең аваз(хәреф)санын дөрес санау күнегүләре эшләү, транскрипцияләү. | 1.12 | |
| 38 | Контроль күчереп язу ” Юлда”. Хаталар өстендә эш. | Файдалы азыклар турында фикер алышу.Текстны күчереп язу. Эшнең дөреслеген тикшерү. | 4.12 | |
| 39 | Графика. Алфавит. | Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. Фонетик зарядка ясау. Сүзләргә фонетик анализ ясау, алфавит тәртибендә урнаштыру. Алфавитны яттан сөйләү. «Кайсы сүз артык?» уенын уйнау, өлешчә эзләнү. Дәреслектәге күнегүләрне төгәл үтәү. | 6.12 | |
| 40 | Графика. Алфавит. Ныгыту. | | 8.12 | |
| 41 | Үткәннәрне кабатлау. Тест биремнәре эшләү. (102-104 битләр) | Кагыйдәләрне искә төшерү. Тест биремнәрен үтәү. | 11.12 | |
| 42 | Сүз | Дәреслектән һәм карточкадан күнегүләр үтәү, Татар теленең “орфографик сүзлеге» белән эшләү. Өлешчә эзләнү. Сүзләрне авазларга таркату чагыштыру. | 13.12 | |
| 43 | Сүзнең тамыры | Сүзнең башка кисәкләргә бүленми торган өлешен табуга күнегүләр эшләү. Төркемнәрдә тиен турында хикәя төзеп сөйләү. Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. Сорауларга җавап бирү, күнегүләр эшләү. | 15.12 | |
| 44 | Сүзнең тамыры | | 18.12 | |
| 45 | Контроль диктант “Кыш”. (2 нче чирек) | Грамматик биремле диктант язу. | 20.01 | |
| 46 | Тамырдаш сүзләр | Теманы билгеләү. Максатны ачыклау. Тамырдаш сүзләрне күзәтү,кагыйдә чыгару. Тамырдаш сүзләр ясау. | 22.01 | |
| 47 | “ Кышкы уеннар” дигән темага хикәя төзеп язу | Кышкы уеннарны сурәтләп, тамырдаш сүзләр кулланып хикәя язу. | 8.01 | |
| 48 | Хаталар өстендә эш. Кушымчалар | Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. Сүзнең тамырын, кушымчаларын билгеләү. Шигырьне хәтердән язу. “Аңлатмалы сүзлек” белән эшләү. Теманы билгеләү. | 10.01 | |
| 49 | Сүз ясагыч кушымчалар | Таблица белән эшләү. Сорауларга җавап бирү, сүз ясагыч кушымчалар табуга күнегүләр эшләү.“Кошларга ярдәм итәбез”дигән темага хикәя төзеп сөйләү. | 12.01 | |
| 50 | Сүз ясагыч кушымчалар | | 15.01 | |
| 51 | Искәртмәле диктант “Кыш көне урманда.” | Искәртмәле диктант язу. Кагыйдәләрне кабатлау,грамматик-орфографик анализ ясау. | 17.01 | |
| 52 | Үткәннәрне кабатлау. Өйрәнчек изложение “Кошлар ашату” | Теманы билгеләү, ачыклау. Изложение текстын сөйләү. Сүз һәм җөмләләрне аңлап язу. | 19.01 | |
| 53 | Предметны белдерә торган сүзләр. | Предметны белдерә торган сүзләргә сорауны дөрес итеп кую; аларны тексттан аерып алу.Күнегүләрне эшләү. Сорауларга җавап бирү,“Аңлатмалы сүзлек”,”Дөрес яз”сүзлекләре белән эшләү. Спорт төрләре турында хикәя төзеп сөйләү | 22.01 | |
| 54 | Предметны белдерә торган сүзләр. Кабатлау | | 24.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 55 | Искәртмәле диктант   “Куян”. | Аерым кагыйдәләргә туры килә торган сүзләрнең дөрес язылышын тикшереп,кабатлау. Аерым кагыйдәгә туры килгән сүзләрне генә язу. | 26.01 | |
| 56 | Исем һәм фамилияләрдә баш хәреф | Теманы билгеләү.<br>Максатларны ачыклау.<br>Сорауларга җавап бирү, күнегүләр эшләү.<br>“Аңлатмалы сүзлек”  белән эшләү.Үзеңне пөхтә йөртү турында телдән хикәя төзеп сөйләү. | 29.01 | |
| 57 | Ил, шәһәр, авыл, елга, күл исемнәрендә баш хәреф | Ил, шәһәр, авыл, елга, күл исемнәре баш хәрефтән башлап язылуын ачыклау.<br>Сорауларга җавап бирү, күнегүләр эшләү.“Аңлатмалы сүзлек”  белән эшләү, | 31.01 | |
| 58 | Ил, шәһәр, авыл, елга, күл исемнә-рендә баш хәреф темасын ныгыту | Ил, шәһәр, авыл, елга, күл исемнәре баш хәрефтән башлап язылуын язмача дәлилләү.<br>Бирелгән модель буенча җөмләләр төәеп язу. | 2.02 | |
| 59 | Контроль күчереп язу “Башкала” | Текст күчереп язу. | 5.02 | |
| 60 | Хаталар өстендә эш. Хайван кушаматларында баш хәреф | Хаталар өстендә эш эшләү, укытучы аңлатуы, «Татар теленең орфографик сүзлеге» белән эш, рус теле белән чагыштыру, нәтиҗә ясау. Бирелгән текстка хайван кушаматлары өстәп язарга. Эшнең дөреслеген тикшерү | 7.02 | |
| 61 | Хайван кушаматларында баш хәреф темасын ныгыту | Теманы билгеләү.<br>Максатларны ачыклау.<br>Сорауларга җавап бирү, күнегүләр эшләү.Иҗади эш эшләү:хайван кушаматлары кертеп үзеңнең этең яки мәчең турында терәк сүзләр кулланып, сыйфатлама хикәя язу. | 9.02 | |
| 62 | | | 12.02 | |
| 63 | “Ялгызлык сүзләр” темасын  кабатлау | Кагыйдәләрне искә төшерү.”Баш хәрефтән , юл хәрефтән ” уены уйнау.”Буталмышлар илендә” эшлекле уенында катнашу. | 14.02 | |
| 64 | Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр | Сорауларга җавап бирү, күнегүләр эшләү,халык<br>авыз иҗаты белән танышу, “Аңлатмалы сүзлек” белән эшләү | 16.02 | |
| 65 | Ике яки берничә предметның эш-хәрәкәтен белдергән сүзләр | Теманы билгеләү.<br>Максатларны ачыклау.<br>Сүзләрне төркемләүгә күнегүләр эшләү. | 19.02 | |
| 66 | Җөмләнең туплаучы  үзәге | Теманы билгеләү.Максатларны ачыклау.<br>Сорауларга җавап бирү, күнегүләр эшләү .Дәреслектәге күнегүләрне эшләү.Теманы билгеләү. | 21.02 | |
| 67 | Җөмләнең туплаучы  үзәге | | 26.02 | |
| 68 | Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр | Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, күнегүләр эшләү. Аерым кагыйдәләргә туры килә торган сүзләрнең дөрес язылышын тикшереп, кабатлау.Аерым  кагыйдәгә туры килгән сүзләрне генә язу.Дәреслектәге күнегүләрнеэшләү.Модельгә туры килүче җөмләләрне сайлап алу. Дидактик уен уйнау.” Эшме? Хәрәкәтме?” | 28.02 | |
| 69 | Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр. | | 2.03 | |
| 70 | Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр темасын ныгыту. Сайланма диктант “Балыкта” | Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, күнегүләр эшләү. Аерым кагыйдәләргә туры килә торган сүзләрнең дөрес язылышын тикшереп,кабатлау.<br>Аерым кагыйдәгә туры килгән сүзләрне генә язу. | 5.03 | |
| 71 | “Ял көнендә” диган темага хикәя төзеп язу | Гаиләнең ял көне турында хикәя төзеп сөйләү һәм дәфтәргә язу. | 7.03 | |
| 72 | Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр темасын кабатлау. | Максатны билгеләү. Өйрәнгән материалны кабатлау .”Зирәк чәүкә”хикәясе буенча сорауларга җавап алу.Тест биремнәре үтәү. | 9.03 | |
| 73 | Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр темасын | Максатны билгеләү .Өйрәнгән материалны кабатлау.”Зирәк чәүкә” хикәясе буенча | 12.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кабатлау. | сорауларга җавап алу.Тест биремнәре үтәү. | | |
| 74 | Билгене белдерә торган сүзләр | Теманы билгеләү.Максатларны ачыклау.Таблица буенча эшләү.Күнегүләр эшләү. | 14.03 | |
| 75 | Билгене белдерә торган сүзләр кертеп “Минем әни”темасына хикәя язу | Бирелгән җөмләләрнең моделен төзү.“Минем әни” дигән темага хикәя төзеп язу. | 16.03 | |
| 76 | Контроль диктант “Язгы ташу” (3 нче чирек) | Грамматик биремле диктант язу. | 19.03 | |
| 77 | Нинди? соравына җавап бирә торган сүзләр предметларның төрле билгеләрен белдерәләр Контроль сүзлек диктант | Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, күнегүләр эшләү.Сүзлек диктанты язу. “Дөрес яз”сүзлеге белән эшләү.Дидактик уен уйнау.“ Кем тизрәк?”. Сайлап алынган предметның билгеләрен санап иҗат эше башкару. | 21.03 | |
| 78 | Билгене белдерә торган сүзләр | | 23.03 | |
| 79 | Билгене белдерә торган сүзләр темасын ныгыту | Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, күнегүләр эшләү. Аерым кагыйдәләргә туры килә торган сүзләрнең дөрес язылышын тикшереп, кабатлау. Аерым кагыйдәгә туры килгән сүзләрне генә язу. | 4.04 | |
| 80 | Билгене белдерә торган сүзләр темасын ныгыту | | 6.04 | |
| 81 | Рәсем буенча хикәя төзеп язу “Кошларны каршы алабыз” | Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. Сорауларга җавап бирү. План төзү. План буенча сочинение язу. | 9.04 | |
| 82 | Хаталар өстендә эш. Үткәннәрне кабатлау | Хаталар өстендә эш эшләү, укытучы аңлатуы, әңгәмә, фонетик зарядка ясау, орфоэпик күнегүләр үтәү, «Татар теленең орфографик сүзлеге» белән эш, рус теле белән чагыш-тыру, нәтиҗә ясау.Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, күнегүләр эшләү. | 11.04 | |
| 83 | Җөмлә | Таблица белән эшләү.Биремнәрне парларда тикшерү.Бирелгән сүзләрдә җөмләләр төзү “Кемнеке күбрәк? Эшлекле уенында катнашу. | 13.04 | |
| 84 | Җөмлә төрләре | Терәк сүзләр белән җөмләләр уйлау. Тыныш билгеләренә карап җөмлә төрләрен билгеләү Дидактик уен уйнау.“ Текстны җөмләләп укыганны тыңлау һәм язу. Дәреслектәге күнегүләрне эшләү. | 16.04 | |
| 85 | Җөмләнең иясе һәм хәбәре | Таблица белән эшләү.Теманы билгеләү.Максатларны ачыклау.Күнегүләр эшләү. Яңа төшенчәләр белән танышу. | 18.04 | |
| 86 | Җөмләнең иясе һәм хәбәре | Таблица белән эшләү.Теманы билгеләү.Максатларны ачыклау.Күнегүләр эшләү. Яңа төшенчәләр белән танышу. | 20.04 | |
| 87 | Җөмләдә сүзләр бер-берсенә бәйләнеп килә | Сөйләмне җөмләләргә аеру. Баш кисәкләрне табып, сызыклар белән билгеләү. | 23.04 | |
| 88 | Җөмләне тикшерү тәртибе | Җөмләне тикшерүнең тәртибе барлыгын исбатлау. Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, күнегүләр эшләү. Дәреслектәге күнегүләрне эшләү | 25.04 | |
| 89 | Җөмлә темасын ныгыту | Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, күнегүләр эшләү.Сорауларга җавап бирү. Дәреслектәге күнегүләрне эшләү. | 27.04 | |
| 90 | Тема: «Җөмлә» Контроль диктант “Җәй” | Киләчәктә нинди һөнәр иясе булырга теләү турында әңгәмәдә катнашу. Текстны күчереп язу. | 30.04 | |
| 91 | Бәйләнешле сөйләм | Текстның өлешләрен :башламы, төп , йомгаклау өлешл Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау. Сөйләм төрләрен искә төшерү.Күнегүләр эшләү.әрен табу. | 2.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 92 | Текст. Текстның темасы. Контроль сүзлек диктанты | Текст өстендә эшләү.<br>Текстны өлешләргә бүлү күнегүләре эшләү.Тема билгеләү.Текстка исем кушу.Биремнәрне парларда тикшерү. | 4.05 | |
| 93 | Текстның өлешләре | Текстны өлешләргә бүлү күнегүләре эшләү. Укылган өзеккә, хикәя һәм сорау җөмләләр кулланып, план төзү, сөйләп карау. | 7.05 | |
| 94 | Хат язу. | Текстның башламы, төп өлеше, йомгаклау өлеш-<br>ләрен кулланып, хат язу тәртибенә нигезләнеп хат язу. Туганнарга һәм дус-ишләргә хат язу тәртибе турында сөйләшү. Г.Тукай хатларын укып фикер алышу. | 11.05 | |
| 95 | Бәйләнешле сөйләм темасын ныгыту.Тәбрик-намә язу. | Сорауларга җавап бирү. Теманы билгеләү. Максатны ачыклау.<br>Туганнарга һәм дус-ишләргә котлау открыткасы язу тәртибе турында сөйләшү.<br>Тәбрикнамә эчтәлеге белән танышу. Тәбрикнамә язарга өйрәнү. | 14.05 | |
| 96 | Контроль изложение “Комсыз эт” | Теманы билгеләү. Максатларны ачыклау.Сорауларга җавап бирү. План төзү, шуның буенча изложение язу. | 16.05 | |
| 97 | Хаталар өстендә эш. Үткәннәрне кабатлау | Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, күнегүләр эшләү. Аерым сүз яки сүзтезмәнең нинди кагыйдә нигезендә язылуын аңлату. Теманы билгеләү. Максатны ачыклау. | 18.05 | |
| 98 | Контроль күчереп язу “Табигать нәрсә ул?” | Җәйге ял турыда әңгәмәдә үткәрү.Укытучы укыганын тыңлау,сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау.Диктант язу. Биремнәр үтәү. | 21.05 | |
| 99 | Административ (йомгаклау) контроль диктанты | Еллык материал буенча белемнәрне язмача рәвештә дәлилләү. Административ контроль диктант язу. | 23.05 | |
| 100 | Хаталар өстендә эш. | Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, күнегүләр эшләү | 25.05 | |
| 101 | “Авазлар һәм хәрефләр” темасын кабатлау | Еллык материал буенча белемнәрне язмача рәвештә дәлилләү.. | 28.05 | |
| 102 | “Җөмлә” темасын кабатлау | Еллык материал буенча белемнәрне язмача рәвештә дәлилләү.. | 30.05 | |

**Укыту- методик әсбаплар исемлеге**

**Әдәбият исемлеге**

**I.Төп:**

1. Мияссарова И. Х., Фәйзрахманова К. Ф. “Татар теле ”дәреслеге: 2нче сыйныф-1-2 кисәк: Казан, “Мәгариф - Вакыт” нәшрияты, 2012нче ел;
2. Мияссарова И. Х.,Фәйзрахманова К. Ф. Татар теленнән мөстәкыйль эш дәфтәре-Казан, “Мәгариф- Вакыт” нәшрияты, 2012 нче ел;
3. Мияссарова И. Х.,Фәйзрахманова К. Ф.Татар теле. Укытучылар өчен методик кулланма -Казан, “Мәгариф- Вакыт” нәшрияты, 2012 нче ел.

**II.Өстәмә:**

1.Абдрәхимова Я. Х. “Татар теленнән диктантлар” 1-4 класс. Казан: “Мәгариф” - 2009.
2.Вагыйзов С. Г. “Кызыклы грамматика” Казан: “Мәгариф” - 2002.
3.Татар  теленең орфографик сүзлеге. Казан “Мәгариф” нәшрияты. 2010. К.Р. Галиуллин, Р.И. Раскулова
4. Ганиев Ф.Ә. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 2005.

**IV. Интернет – ресурслар**

татар электрон библиотекасы http://kitap.net.ru/;
татар телендә интернет белем үзәге http://belem.ru//;
балалар өчен сайт http://balarf.ru/.
https://edu.tatar.ru/el_books- әлифба